КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1284

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» пилот проектын тормышка ашыру турында» 2016 ел, 31 август, 604 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» пилот проектын тормышка ашыру турында» 2016 ел, 31 август, 604 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 март, 157 нче, 2017 ел, 8 декабрь, 961 нче; 2018 ел, 5 апрель, 208 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның беренче абзацында «(60 яшьтән өлкән ир-ат, 55 яшьтән өлкән хатын-кыз)» сүзләрен «, «Иминият пенсияләре турында 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге юридик хокуклы гражданнар өчен тәрбиягә алган гаилә төзү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктта:

икенче абзацта «(60 яшьтән өлкән ир-ат, 55 яшьтән өлкән хатын-кыз)» сүзләрен «, «Иминият пенсияләре турында 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «60 яшькәчә хезмәткә сәләтле яшьтәге балигъ булган юридик хокуклы граждан» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә лык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җитмәгән юридик хокуклы хезмәткә сәләтле балигъ булган граждан» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин